# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Конституциясенең**
**75, 76, 94 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 12 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Конституциясенә (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 9-10; 1994, № 11; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, № 2-3, № 12; 1996, № 11; 1999, № 6, № 8 (I өлеш); 2000, № 3 (3), № 6 (5), № 12 (10) I өлеш; 2001, № 7-8; 2002, № 3-4; 2003, № 9 (I өлеш); 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 75 статьяга түбәндәге эчтәлекле $22^1$ пункт өстәргә:

"$22^1$) Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесен билгеләп кую;";

2) 76 статьяның беренче өлешендәге беренче җөмләсендә "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты," сүзләреннән соң "Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе," сүзләрен өстәргә;

3) 94 статьяга түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

"$9^1$. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе вазыйфасына кандидатура тәкъдим итә;".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 30 марты
№ 10-ТРЗ